**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ул. Ленина, д.76 а, с.Беркет-Ключ,**
**Черемшанский район, 423106**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

**Ленин урамы, 76 а йорты,**
**Бәркәтә авылы,**
**Чирмешән районы, 423106**

тел./факс +8(84396)
2-64-66
Email Berk.Cmn@tatar.ru

**№2** **18.12.2023 ел**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә янгын күзәтчелегенең социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә өстәмә ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ, «Ирекле янгын күзәтчелеге турында» 2011 елның 6 маендагы № 100-ФЗ Федераль законнарга, «Татарстан Республикасында ирекле янгын күзәтчелеге турында» 2011 елның 1 августындагы №48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәрәктә авыл җирлегендә ирекле янгын күзәтчелеген үстерү өчен кирәкле шартларны булдыру максатларында **КАРАР КЫЛДЫМ:**

1. Ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм ирекле янгын сүндерү хезмәткәрләренә түбәндәге ташламалар һәм ярдәм чаралары бирергә:

- Җирлек бюджеты хисабына финанслана торган мәдәни чараларга бушлай йөрү;
- янгын сүндергәндә һәм гадәттән тыш хәл режимында авария-коткару эшләрен үткәргәндә ирекле янгын күзәтчелеге әгъзаларын туклану белән тәэмин итү.

2. Ирекле янгын сүндерүчеләрнең эшчәнлеген матди һәм әхлакый стимуллаштыру:

Янгыннарны профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә һәм авария-коткару эшләрен үткәрүдә түләүсез нигездә катнашучы ирекле янгын сүндерүчеләрне мораль һәм матди стимуллаштыруның түбәндәге чараларын билгеләргә:

а) муниципаль берәмлек башлыгының рәхмәт белдерүе;

б) кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләү;

в) Муниципаль берәмлек башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү;

Ирекле янгын сүндерүчеләрне стимуллаштыру чараларын финанслау Бәркәтә авыл җирлеге бюджетында каралган акчалар хисабына, шулай ук бюджеттан тыш (спонсорлык) акчалар җәлеп итү хисабына башкарыла.

Предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре үз акчалары хисабына ирекле янгын күзәтчелеге җәмәгать берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр бирә ала.

Ирекле янгын сүндерүчеләрне стимуллаштыру чараларын куллану Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы нигезендә башкарыла.

3. Әлеге карарда каралган ярдәм чаралары ирекле янгын сүндерүчеләр реестрында бер елдан да ким булмаган вакытка теркәлгән һәм Җирлек территориясендә янгыннарны

профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә катнашуга җәлеп ителгән гражданнарга, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең ирекле янгын сүндерүчеләре һәм Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы Р.М.Сибгатуллин